ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының өченче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының өченче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 595-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
3. «Салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемен билгеләү өчен кулланыла торган киметүче коэффициент күләмен билгеләү турында» 592-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «2025 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» 594-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 591-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 599-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 588-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 589-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 590-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 3-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 598-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 593-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 597-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Россия Федерациясеннән чыгу һәм Россия Федерациясенә керү тәртибе турында» Федераль законны Татарстан Республикасы Дәүләт Советында гамәлгә ашыру хакында.

17. Г.И. Сабирова турында.

18. И.Ф. Фазуллинны «Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәррире вазыйфасына билгеләп кую турында.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 20 сентябре
№ 6-VII ДСП